| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**28.09.2015** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 2002** |

Зеленодольск шәһәренең Кызыл тыкрык урамы буенча 1 нче номерлы йортны сүтелергә тиеш дип тану турында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 31 июлендәге 1553 номерлы «Зеленодольск муниципаль районының авария хәлендәге күпфатирлы йортлар исемлеген раслау турында»гы карары, шулай ук бинаны торак урыны, торак урынын - даими яшәү өчен яраксыз дип тану буенча ведомствоара комиссиянең 2011 елның 15 ноябрендәге 28 номерлы бәяләмәсе нигезендә, Россия Федерациясе Граждан кодексы, Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы «Урынны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йорт авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану турындагы нигезләмәне раслау хакында» 47 номерлы карарына таянып, Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск шәһәренең Кызыл тыкрык урамы буенча 1 нче номерлы йортны сүтелергә тиеш дип танырга
2. ЭПУ «Зеленодольскгаз», «ЗВКС» АЖ, ОКО Идел буе бүлекчәсе - «Татэнергосбыт» ААЖ Зеленодольск шәһәренең Кызыл тыкрык урамындагы 1 нче йортны тиешле төрдәге коммуникациядән өзәргә.
3. Зеленодольск шәһәренең Гагарин урамындагы 176 фатирлы йорт, Полукамушки мкр. төзелешен дәвам итү максатында, «Восход» ҖЧҖтүбәндәгеләрне түләүсез тормышка ашырырга тәкъдим итәргә:

-күрсәтелгән йортны сүтәргә;

-йортны сүткәннән соң төзелеш чүп-чарын чыгарга;

- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына йортны сүтү турында актны тапшырырга.

4. «Зеленодольск муниципаль районының торак-коммуналь хуҗалыгы департаменты» МБУ Зеленодольск шәһәре, Кызыл тыкрык урамы, 1 нче йорт 2, 4 кв. адресы буенча торак урыннарының социаль наем шартнамәләрен өзәргә.

5. «Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МУ Зеленодольск шәһәренең Кызыл тыкрыг урамындагы 1 нче йортны билгеләнгән тәртиптә муниципаль милек реестрыннан төшереп калдыруны тәэмин итәргә.

6. ЗМР Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгы А.Н. Коршуновка әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларының Зеленодольск муниципаль районының интернет челтәре сайтында һәм «Зеленодольская правда». газетасында урнаштыру юлы белән тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче С.Г. Егоров